РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

28 март 2024 ел №238

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе һәм сроклары турында» 2019 елның 18 июлендәге 238 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы № 480-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 9 декабрендәге №124-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 18 июлендәге 238 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктның 2 нче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «- гражданның мөрәҗәгате - Чирмешән муниципаль районының җирле үзидарә органнарына яисә Чирмешән муниципаль районының җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларына язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - Бердәм портал) кулланып җибәрелгән тәкъдим, гариза яки шикаять, ә шулай ук гражданның Чирмешән муниципаль районының җирле үзидарә органнарына телдән мөрәҗәгать итүе».

1.2. 4.1 нче пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «4.1. Гражданның язма рәвештә язылган мөрәҗәгатендә мөрәҗәгать җибәрелгән органның исеме, яисә тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, яки тиешле затның вазифасы, шулай ук тәкъдим, гариза яки шикаятьнең асылы, гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булганда), җавап, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәр җибәрелергә тиешле почта адресы яки электрон почта адресы яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланганда шәхси кабинет адресы (уникаль идентификатор) (алга таба - шәхси кабинетның адресы Бердәм порталда), шәхси имза һәм дата булырга тиеш.».

1.3. 4.3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «4.3. Әгәр язма мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгатьне җибәргән гражданның фамилиясе яки адресы (почта адресы, электрон почта адресы яки Бердәм порталда шәхси кабинет адресы) күрсәтелмәсә, мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Әгәр дә әлеге мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, башкарыла торган яки башкарылган законсыз гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яки кылган кеше турында мәгълүматлар булса, мөрәҗәгать дәүләт органына аның компетенциясенә ярашлы рәвештә җибәрелергә тиеш.».

1.4. 4.6 нчы пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «4.6. Җирле үзидарә органына яки вазифаи затка электрон документ рәвешендә килгән мөрәҗәгать законнарда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан үзенең фамилиясен, исемен, әтисенең исемен (соңгысы булганда), электрон почта адресын, яки Бердәм порталда шәхси кабинет адресын, әгәр җавап электрон документ формасында җибәрелергә тиеш булса, һәм җавап язма формада җибәрелергә тиеш булса, почта адресын күрсәтергә тиеш. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон формада кушарга яки күрсәтелгән документларны һәм материалларны яки аларның күчермәләрен язма формада җибәрергә хокуклы.».

1.5. 7.4 нче пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «7.4. Мөрәҗәгатькә җавап электрон документ рәвешендә җибәрелә, шулай ук электрон почта адресын күрсәтә яки электрон документ рәвешендә җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән Бердәм порталда шәхси кабинет адресын (уникаль идентификатор) куллана һәм язма рәвештә җирле үзидарә органына яки вазифаи затка кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма формада җибәрелә. Моннан тыш җирле үзидарә органнарына яки вазифаи затка кергән билгесез даирә затларның мәнфәгатьләренә кагылган тәкъдимне, гаризаны яки шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатькә, аерым алганда, билгесез даирә затларга карата чыгарылган суд карарына шикаять белдергән мөрәҗәгатькә җавап, шул исәптән суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясының 2 өлеше таләпләрен үтәп, җирле үзидарә органнарының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылга мөмкин.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башлыгы урынбасарына, Совет рәисе урынбасарына йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов